ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ
ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕ

Айдар
ФӘЙЗРАХМАНОВ

# ҖЫРЫМ БУЛЫП КАЛЫРСЫҢ...

*җырлар һәм романслар*

КАЗАН
2021

**Фәйзрахманов А. Ф.**
**Җырым булып калырсың...: җырлар һәм романслар**

Кереш мәкалә авторы, җыентыкны төзүче –
Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты,
профессор, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты,
Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең һәм
Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт
ансамбленең сәнгать җитәкчесе А. Ф. ФӘЙЗРАХМАНОВ

РЕДКОЛЛЕГИЯ:
Рецензентлар С. Ю. Әхмәтҗанова, Р. Г. Рәхмәтуллин
Мөхәррире Г. Ф. Шәрапова
Музыкаль мөхәррире И. Ф. Камалов

Әсәрләрне фортепианога кушылып башкару өчен
композитор Ильяс Камал эшкәртте.

**Фәйзрахманов А.Ф.**
«Җырым булып калырсың...»: җырлар һәм романслар – Казан: «Халкыбыз мирасы» нәшрияты, 2021. – 126 б.

ISMN 979-0-9003340-1-5
© А. Ф. Фәйзрахманов. 2021 ел.

# ИҖАДИ ЮЛЛАМА
## (ӘЙТЕР СҮЗЕМ БАР)



Замана бик төрле… Күп хәрәкәт, үзгәреш, техник камилләшү, көнкүреш чуарлыгы, милләтара, дөньякүләм аралашу – берникадәр буталу бара. Кыйбла кайда соң?!

Милләтнең телен, моңлы аһәңен, аның милли асылын саклап кала алырбызмы?.. Бу сораулар, әлбәттә, битараф калдыра алмый, һәм дә синең хакың да юк. Син үз халкыңның асыл вәкиле булып яшәргә, башка кавем, бүтән милләт вәкилләрен сокландырырга, үзеңә җәлеп итәргә тиешсең. Бу мөмкинме, гомерең җитәрме, һәм моның өчен син нинди булырга тиеш соң?!

Мин исә, замананың төрле тискәре үзгәрешләренә каршы торып, үземчә, халкымның асыл милли хәзинәсенә таянып иҗат итәм.

…Шатлык-кайгылар, туу-үлемнәр –
Барысы да бер гомер эчендә…

Әлеге җыентыгыма Равил Фәйзуллинның шигъри фәлсәфәсенә таянып, төрле авторларның шигырьләренә иҗат ителгән җырларым тупланган. Алар – минем күңел халәтемнең чагылышы; соңгы берничә ел эчендәге кичерешләрем, шатлыкларым, сагышларым. Җырларның шигырь авторлары – минем замандашларым. Аларның күңел кичерешләре, шәхси фәлсәфәләре минем эчке халәтем белән бик тә тәңгәл киләләр, мөгаен, шуңа күрә дә алар җырга әйләнгәндер дә. Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Роберт Әхмәтҗанов, Рәшит Әхмәтҗанов, Разил Вәлиев, Мөхәммәт Мирза, Сания Әхмәтҗанова, Кадыйр Сибгатуллин, Җәүдәт Сөләйман… – алар минем җыр чишмәмнең башы.

Көй агылышы, гармония, музыкаль фактура, диапазон дигән төшенчәләргә таянып иҗат ителгән бу әсәрләрем, җырчы дустым, инде сиңа тәкъдим ителделәр. Әлбәттә, мин синнән бу җырларга бик игътибарлы булуыңны үтенәм. Авторларның ни әйтергә теләгәннәрен күңелең белән тоеп, йөрәгең аша үткәреп, киң тамашачыга җиткерүеңне ишетсәм, күрсәм вә дә сөенсәм иде. Төп музыкаль кануннарга, шигъри юлларга ихтирамлы булып, аларны ватмый-чәчми иҗат кылсаң иде. Милли хәзинәбезне вату, аның асылын тоймау, халкыбызның «алтын фонд»ын тәшкил иткән җырларны үзгәртергә тырышу бүгенге көндә бик күп башкаручыларның иҗатында чагыла. Бу бик тискәре күренеш. Ә мин сиңа зур өметләр баглыйм.

Җырларыбызның һәр авазы халкыма барып җитеп, аның күңелендә үзенең милли, горур үсентеләрен бирсен иде. Мин моңа ышанам!!!

*Россиянең атказанган,*
*Татарстанның халык артисты,*
*Татарстан Республикасының*
*Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты*
Айдар ФӘЙЗРАХМАНОВ.

# КАБАТЛАНМАС АҺӘҢЛЕ ИҖАТ



...Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә күптән сагынып көтелгән концерт бара. Сәхнә түрендәге экранда, җыр-көйләр эчтәлегенә туры китереп, заманча бизәлешле, күз явын алырлык күренешләр берсен берсе алмаштыра. Менә, Сөембикәле нугай даласының йөрәк тибешен хәтерләтеп, кушаяклап чапкан атлар тоягыннан чорлар тузаны кубарылып калгандай була; менә борынгы Кол Шәриф мәчетенең зәңгәрсу-фирүзә гөмбәзедәй биниһая күктә, вакыт көчешен искәртеп, каурый-каурый ак болытлар ташкыны агыла... Тыйнак-тыенкы курай авазына еламсар җил шыңшуы килеп сарылгандай була.

...Ак болытны юлдаш итәр идем,
Хәлләремне әгәр аңласа.
Шул болытлар белән китәр идем,
Туган-үскән җирләр калмаса...

Сәхнәдә – яшь җырчы Илгиз Мөхетдинов, бәгырьнең иң тирән төпкелләренең үтә яшерен почмакларындагы сагышлы өермәне кузгата-уята... Җырдагы «яңгыр микән, әллә кар микән» дигән урыннарда керфек очларына, әйтерсең лә, шул карлы яңгырның кайнар тамчылары эленә...

Җыр сүзләре авторы Илдар ага Юзеевча әйтсәк, «үз-үземне тыеп кына калам» – күңел шул иксез-чиксез болытлар итәгенә сыенып, күз күрмәгән ерак җирләргә агылгандай була... Көй бөтенләй үзгә, кабатланмас аһәңнәр тылсымлы моң белән өртелгән, алар гүя сихерле-әсәрләндерә... Ул аһәңнәр шагыйрь хисләренең җан тибеше кебек тоела. Көй һәм сүзләр шулкадәр бер-берсенә тәңгәл килгән ки, җырчы егетебез дә шушы бербөтенлекне үз йөрәге, җаны-тәне аша үткәреп, сәхнәдә җырны яшәтә, «җанны яралаучы күп дөньяда, җанны дәвалаучы бар микән?» дип өзгәләнә. Җырда, башкаруда, бизәлешләрдә барысы да бөтен нечкәлекләренә кадәр уйланылган, зәвык белән балкытылган, әфсенле сулыш өреп шомартылган, тиешле формага китерелгән. Таләпчәнлек үзен һәр ымда, һәр хәрәкәттә сиздереп тора; җырмы, биюме, нәфис сүзме – чыгышларның һәркайсы профессиональ югарылыкта тәкъдим ителә.

...Без – якташыбыз, Арча районының Урта Бирәзә авылында туыпүскән, тиешле һөнәри белем-тәҗрибә туплап, Казан федераль университеты профессоры дәрәҗәсенә ирешкән, филармониянең һәм Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбленең сәнгать җитәкчесе Айдар Фәтхрахман улы Фәйзрахмановның 65 яшьлек юбилей концертында. Инде тыңлаган һәм әле яңгыраячак җырларның көен дә ул – Россиянең атказанган,

Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов үзе язган. Сүз авторлары кемнәр диген?! Әйткәнемчә, Илдар Юзеев, тагын Роберт Әхмәтҗанов, Мөдәррис Әгъләмов, Равил Фәйзуллин, Разил

Вәлиев... Концертта башкарылган дистәләрчә җыр һәм романслар арасында үземнең сүзләргә язылганнары да булуы миндә аеруча зур горурлык уятты. Үзем өчен дә, хәтта Айдар абый өчен генә дә түгел... Данлы Арчабыз, уртак төбәгебез, Айдар Фәтхрахман улы кебек талантлы уллар-кызлар биргән туган туфрагыбыз өчен горурлык хисе иде ул!

Гап-гади бер авылда ишле гаиләдә тәрбияләнеп, башта авыл мәктәбендә укыган, аннан Арчада гадәти урта мәктәпне тәмамлаган егет, югары музыкаль белем алып, 27 ел опера җырчысы булып эшли, музыка уен коралларында осталарча уйнауга ирешә, республикабызның дәүләт фольклор музыкасы ансамблен җитәкли. Сәнгать белгечләре билгеләп үткәнчә, бик кыска вакыт эчендә ансамбль республикада гына түгел, чит илләрдә дә татар халкының милли сәнгатен лаеклы дәрәҗәдә күрсәтә алырлык профессиональ коллектив булып формалаша.

...Һәм менә без Айдар Фәйзрахмановның җырлы-биюле, нәфис сүз белән чигелгән милли бизәкле күркәм гомер сәхифәләренең тамашачы-шаһиты. Концерт талантлы якташым көй язган уртак җырыбызның исеме белән аталган: «Тәгәри тормыш арбасы». Ә гомер олавына тырышлык, эзләнүләр бәрабәренә килгән табышлар, уңышлар, казанышлар, ә иң кадерлесе – халкыбызның билгеле һәм әле яңа гына табылган борынгы фольклор әсәрләре үрнәкләре, милли хәзинәбез тупланган. Өстәвенә, шушы байлыкка танылган татар шагыйрьләре – чын каләм осталары сүзләренә Айдар Фәйзрахманов үзе көй иҗат иткән җыр һәм романсларыннан, авторның инструменталь әсәрләреннән торган ноталы берничә җыентык-альбомны да кушсак, киләсе буыннарга тапшырылачак җыр-моң мирасының бибәһа кыйммәткә ия булганын аңларбыз.

Әлеге концерттан соң елдан артык кына вакыт узуга да карамастан, тиңсез хәзинәле «олавыбыз» кулыбыздагы тагын бер ноталы альбом – Айдар Фәйзрахмановның 35 өр-яңа музыкаль әсәрен үз эченә алган «Җырым булып калырсың» дигән җыентыгы белән тулыланды. Тагын бер ел гомер халкыбыз, туган телебез, милли көй-моңнарыбызны яшәтү-саклау өчен иҗтиһад-тырышлыкка багышланган.

Тормыш арбасы тәгәри... Нинди генә үрләргә менсәң дә, нинди генә биеклекләр яуласаң да, гомереңнең кайсы фасылына аяк атласаң да, «Төп йортым» дип (Роберт Әхмәтҗанов сүзләре) моңланмый калып буламы? «Туган туфрак җылысы» (Сания Әхмәтҗанова сүзләре) үзен онытгырырмы? Үз-үзеңә «Бор атыңны» (Шәмсия Җиһангирова сүзләре) дип дәшмәскә көч таба алырсыңмы? Бу җыр-көйләр олпат яшькә җиткән ир-егетнең хис дәрьясын ташыткан сагыш дулкыннары пышылдавын да, күңел тәрәзенә сарылып, язгы төннәрдә татлы йокысын урлаган сыерчык бураны салкынын да, өмет булып сирпелгән җәйге таң нурлары балкышын да сыйдырган... Ә ул хискичерешләрнең исемнәре – «Сагыш» (халык сүзләре), «Язгы буран» (Разил Вәлиев сүзләре), «Ышаныч» (Равил Фәйзуллин сүзләре) һәм серле яңгырашлы башка бик күп көй-төсмерләр.

Шулай да, бу яңа язылган җырларга салынган иң якты хис – ул сөю, ярату хиседер, мөгаен. Альбомның исеме юкка гына «Җырым булып калырсың» түгелдер... Гөлбишектә тирбәтерлек булып кадерләгән мәхәббәт алиһәң сине мәңгелеккә калдырып киткәч тә, яраланган коштай бәргәләнгән йөрәгеңне юатырлык көчләр табу, бердәнберең бирген вәгъдәң хакына сыңар канат белән күтәрелү һәм, җырлы-моңлы сәфәреңне, изге максатыңа юлны дәвам иттерү – әнә шул түгелме тугры мәхәббәтнең соңсыз булуының, үлемсезлегенең дәлиле.

Әлеге кабатланмас якты хис сиңа яшәү асылыңны табарга, туган ягыңны, үз халкыңны яратырга – насыйп гомереңне үзеңнән соң да бер матур җыр булып калырлык итеп кичәргә көч бирә. Нәкъ Айдар Фәйзрахмановның шушы яңа альбом-җыентыгындагы үзе моңлы, үзе дәртле, үзе кабатланмас аһәңле җырлар кебек булырлык итеп.

Сания Әхмәтҗанова,
*шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.*

# ЗАТЛЫ ҖЫРЛАР



Миңа, баянчы, «Мирас» инструменталь ансамбле җитәкчесе буларак, җырчылар белән бик күп концертларда катнашырга туры килә. Шулар арасында Айдар Фәйзрахманов авторлыгында уздырылган «Олы юл әйтте...» циклыннан булган концертларда катнашу үзенә бер җаваплылык таләп итә. Тулаем бер автор әсәрләреннән торган әлеге концерт программалары затлы җырлары, профессиональ җырчылары белән аерылып торалар. Алай гына да түгел, зал тулы тамашачыны баштан ахырга кадәр гаҗәеп бер моң эчендә йөздереп, уйланырга, сокланырга, горурланырга өндиләр, милли хисләребезне яңарталар алар.

Ничек алай? Югыйсә, алып баручы да юк, башкарылган әсәрләрнең кыйммәтен ачып бирүче дә юк!? Җавап гади: сәхнәдән яңгыраган җырлар – Айдар Фәйзрахмановның бәгыреннән тамган көй-моңнар. «Йөрәктән чыккан гына йөрәккә барып җитә», – диләр шагыйрьләр. Менә бу җырлар да шулай. Ихлас күңелдә, моңлы күңелдә туган җырлар бу. Операда да, эстрадада да үзенә генә хас башкару осталыгына ирешкән, аз гына вакытка да татар моңыннан аерылмаган, гомерен шуңа багышлаган гаҗәеп шәхес Айдар Фәйзрахманов җырлары бу.

Ни куаныч, әлеге җырлар, фортепиано өчен эшкәртелеп, матур-матур җыентыкларда да чыгып киләләр: «Яшәү барыбер кызык», «Олы юл», «Борчылма» һәм, ниһаять, әлеге җыентык – «Җырым булып калырсың...». Исеме үк моңлы...

Җырлар һәм романслар җыентыгы. Айдар Фәйзрахмановның дүртенче китабы. Аның арабыздан мәңгелеккә киткән сөекле хатыны Халисә истәлегенә багышланган, бүгенге халәтен төгәл тасвирлаган, сыкранган күңеле эзләгән юаныч, таяныч җырлары...

Җыентыкка И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, Роберт Әхмәтҗанов, Р. Вәлиев, Р. Мингалим, Зөлфәт, Х. Әюп, Рәшит Әхмәтҗанов, Ш. Җиһангирова, Л. Зөлкарнәй, М. Мирза, Җ. Сөләйманов,

К. Сибгатуллин, С. Әхмәтҗанова сүзләренә язылган җырлар һәм романслар тупланган. Һичшиксез, алар профессиональ җырчыларның репертуарларында лаеклы урын алырлар. Вокал сер-

ләрен үзләштерергә теләгән яшьләр өчен дә бик кирәкле, файдалы булыр бу җыентык, чөнки татар моңы, аның бормалары (мелизмнар), көй һәм шигырь юлларының тәңгәл килүе, ритмик сурәт, киң диапазон – барысы да А. Фәйзрахманов җырларында профессиональ югарылыкта бирелгән. Тирән мәгънә, фәлсәфи кичерешләр ул җырларда. Айдар Фәйзрахманов җырларын әллә каян танып аласың: алар татар халык көйләренә хас җылылык, җанга якын милли аһәңнәр белән өртелгән, төрле төсмерләргә бай хисләрне чагылдыралар. Музыкаль яктан Айдар Фәйзрахманов җырлары һәм романслары олпат композиторларыбыз Рөстәм Яхин, Сара Садыйкова романслары лирикасын дәвам итәләр. Бу бигрәк тә алардагы гармония һәм фактура, аккомпанемент ритмикасында, көйләрнең интонациясендә ачык чагыла.

Равил Фәйзуллинның бер шигырендә мондый юллар бар:

...Күзем бәйле килеш
Дөнья читләрендә адашсам,
Туган илемне мин табар идем
Сәйдәш көйләренең моңы аша...

Айдар Фәйзрахманов көйләре дә шуңа тиң. Аның җырларын ишеткән кеше, «Бу – татар җыры!» – дип ялгышмыйча әйтә ала; алар милли, чын татарча, күңелебезгә якын.

Рөстәм Рәхмәтуллин,
*Татарстанның атказанган артисты,*
*Н. Җиһанов исемендәге*
*Казан дәүләт консерваториясе доценты,*
*Татарстан Республикасы*
*Халыклар дуслыгы йортының*
*«Мирас» инструменталь*
*ансамбле сәнгать җитәкчесе.*



Айдар
ФӘЙЗРАХМАНОВ

# ҖЫРЫМ БУЛЫП КАЛЫРСЫҢ...

*җырлар һәм романслар*

# Авылда көз

Р. Фәйзуллин

А. Фәйзрахманов




10
Кушымта
Ак кү - мәч. Сөт - ле чәй, чик - лә - век – та - бын - да;
11
Чит-ләр-дән ку-нак-ка кай-та-лар а-выл-га. Шау-лап каз ө-мә-се ү - тә өй бо-рын-ча.
13
1.
Эш - тән соң ке - рер - гә я - гы - ла ак мун - ча!


2.
ак
мун - ча!
mf
Кабатлау өчен
Тәмамлау өчен

2. Чикләвек бик уңды,
Тиенде тиен дә!
Җылылык һәм муллык
Һәркемнең өендә!

<u>Кушымта</u>:
*Ак күмәч. Сөтле чәй,*
*Чикләвек – табында;*
*Читләрдән кунакка*
*Кайталар авылга.*

*Шаулап каз өмәсе*
*Үтә өй борынча.*
*Эштән соң керергә*
*Ягыла ак мунча!*

3. Үзгә бер җыйнаклык
Бакчада, ындырда.
Күңелдә иркенлек –
Хисләргә, моң-җырга.

<u>Кушымта</u>:
*Ак күмәч. Сөтле чәй,*
*Чикләвек – табында;*
*Читләрдән кунакка*
*Кайталар авылга.*

*Шаулап каз өмәсе*
*Үтә өй борынча.*
*Эштән соң керергә*
*Ягыла ак мунча!*

# Ана җыры

С. Әхмәтҗанова

А. Фәйзрахманов




13
Бел - гән до - гам у - кып эч - тән ге - нә, өй тү - ре - мә эл - дем
16
би - ше - гең. Әй ба - лам, ба - гал - мам,
19
бә - хе - тең - не бир - сен бер Ал - лам. Әй ба - лам,
22
ба - гал - мам, тәү - фый - гың - ны бир - сен бер Ал - лам.


Кабатлау өчен
25
mf
29
Тәмамлау өчен
33
mf
35



2. Кайгы – хәсрәт рөхсәт сорап тормый,
Үтә икән өйнең түренә.
Алларыма алып сине сөйсәм,
Ачы хәсрәтем дә сүрелә.

<u>Кушымта</u>:
*Әй балам, багалмам,*
*Бәхетеңне бирсен бер Аллам*
*Әй балам, багалмам,*
*Тәүфыйгыңны бирсен бер Аллам.*

3. Тигез канат җылысына сыенып,
Насыйп булса иде яшәргә.
Соң сулышта, башкаеңнан сыйпап,
Риза – бәхил, диеп дәшәргә.

<u>Кушымта</u>:
*Әй балам, багалмам,*
*Бәхетеңне бирсен бер Аллам*
*Әй балам, багалмам,*
*Тәүфыйгыңны бирсен бер Аллам.*

# Атларга йөгән кидермим...

Ж. Сөләйман

А. Фәйзрахманов




16
га - сыр-лар - да
ак бә-хет - ләр ө - лә - ше –
21
Кушымта:
п, Эх! Ат - лар-га ка - рап кыч-кы - рам:
24
ат - ла-рым, әй - һәй - һәй - һәй! То - як-тан чык-
27
1.
кан а-ваз да кү - ңел-гә ят - кан сүз -


30
Кабатлау өчен
-дәй
//кан
сүз
-
дәй!
mf
Тәмамлау өчен
//кан
сүз
-
дәй!
31
mf
34
1.
2.

2. Атларның тып-тып басуы
Тимер дагадан микән?
Тып-тып итеп, саный-саный,
Гомерләр ага микән?

*Кушымта:*
*Атларга карап кычкырам:*
*Атларым, әй-һәй-һәй-һәй!*
*Тояктан чыккан аваз да*
*Күңелгә яткан сүздәй.*

3. Атлар уйный болыннарда,
Гомердән гомерләргә,
Чирәмгә түгел, эзләре
Уела бәгырьләргә.

*Кушымта:*
*Атларга карап кычкырам:*
*Атларым, әй-һәй-һәй-һәй!*
*Тояктан чыккан аваз да*
*Күңелгә яткан сүздәй.*

4. Таң алдыннан тояк эзе
Чолгана көмеш чыкка,
Тояк тавышы күңелне
Кайтара балачакка.

*Кушымта:*
*Атларга карап кычкырам:*
*Атларым, әй-һәй-һәй-һәй!*
*Тояктан чыккан аваз да*
*Күңелгә яткан сүздәй.*

# Атларым-канатларым

Х. Туфан

А. Фәйзрахманов




17
Без шу - лар - да гиз - гән и -
21
дек сез - дә, да - ла җил - лә - ре;
25
Кушымта:
Пе - га сым син, тул - па - рым син, нәф - рә - тем - мә -
Тик бү - ген бит, тик бү - ген мин тәкъ - дим и - тәм
29
хәб - бә - тем! – шигъ - ри ил - һам дип а - тал - ган иң мө - кат - дәс
рәх - мә - тен. Син га - фу ит соң - ла - вым - ны, нәф - рә - тем - мә -


33
Кабатлау өчен
Тәмамлау өчен
нәр - сә - нең, –
//хәб - бә - тем...
36
39
41

1. Атларымның тезләрендә
Иске яра эзләре...
Без шуларда гизгән идек
Сездә, дала җилләре;

<u>*Кушымта*</u>*:*
*Пегасым син, тулпарым син,*
*Нәфрәтем-мәхәббәтем! –*
*Шигъри илһам дип аталган*
*Иң мөкатдәс нәрсәнең, –*
*Тик бүген бит, тик бүген мин*
*Тәкъдим итәм рәхмәтен.*
*Син гафу ит соңлавымны,*
*Нәфрәтем-мәхәббәтем...*

2. Шигъри Тауга тик шунарда,
Пар канатта бар фәкать;
Тик шунарга үз булуда
Һәр әдәби бәрәкәт.

<u>*Кушымта*</u>*:*
*Пегасым син, тулпарым син,*
*Нәфрәтем-мәхәббәтем! –*
*Шигъри илһам дип аталган*
*Иң мөкатдәс нәрсәнең, –*
*Тик бүген бит, тик бүген мин*
*Тәкъдим итәм рәхмәтен.*
*Син гафу ит соңлавымны,*
*Нәфрәтем-мәхәббәтем...*

# Ашкыну

Р. Фәйзуллин

А. Фәйзрахманов




14
ны күрәм дә, күңелем ерак-ка, ерак-ка аш-кы-на.
17
Җир ма-тур, Җир гү-зәл, тик аны кадер-ләп, сер-ләрен
20
ач кы-на. Дәрт тулы күңелем
23
1.
2.
бар-сын да белер-гә, күрер-гә аш-кы-на. //аш-кы-на.
mf




2. Ышанып киләчәк тормышка,
Сокланып кешеләр гыйшкына, –
Җыр тулы тынгысыз күңелем
Яшәргә, яшәргә ашкына.

<u>*Кушымта*</u>*:*

*Җир матур, Җир гүзәл, тик аны*
*Кадерләп, серләрен ач кына.*
*Дәрт тулы күңелем барсын да*
*Белергә, күрергә ашкына.*

# Әнием

Ж. Сөләйман

А. Фәйзрахманов




8
ем,
Дәрь - я - лар - ны ү - тәм, ки - чәм и - сән - и - мин,
10
кү - це - лем - дә бул - гач син, Ә - ни - ем.
12
Ә - ни - ем – ак ка - на - тым ми - нем, Ә - ни - ем –
5
15
1.
2. Кабатлау өчен
моң ка - на - тым ми - нем.
моң ка - на - тым ми - нем.


17
19
2. Тәмамлау өчен
//моң ка - на - тым ми - нем.
mf
21
22
rit.

2. Чәчләреңнән сыйпыйм ерак-еракларда,
Көмеш чәчләреңә кирәкми шәл,
Юлларыңны югалтмыйсың, ялгышмыйсың,
Ай-кояшлы күнелеңә кирәкми шәм.

*<u>Кушымта</u>:*
*Әнием –*
*Ак канатым минем,*
*Әнием –*
*Моң канатым минем.*

3. Акыл белән, бәгырь белән тоям, Әни,
Аңлашырга диеп дәшә күңел,
Мин бит җиргә, Әни, син китергән өлеш,
Безне аерулар мөмкин түгел.

*<u>Кушымта</u>:*
*Әнием –*
*Ак канатым минем,*
*Әнием –*
*Моң канатым минем.*

# Әнкәйнең чәчәкләре

Рәшит Әхмәтҗанов А. Фәйзрахманов




17
Кай - гың-ны та - рат - ка - нын. Зәң - гәр чә - чәк-
21
ләр – шат-лы - гың, са - ры-сы – са-гыш - ла - рың...
24
И - ше-тәм: – Ән - кәй са-гын - ган,
26
кайт, – ди-гән та - выш - ла - рын.
3




2. Походта чакта аларны
   Мин эзләп, күзләп үтәм.
   Кайгыларың таралса да,
   Сагышың исән икән.

<u>Кушымта</u>:
   *Зәңгәр чәчәкләр – шатлыгың,*
   *Сарысы – сагышларың...*
   *Ишетәм:*
   *– Әнкәй сагынган,*
   *Кайт, – дигән тавышларын.*

3. Һавадан да килә тавыш,
   Һәм җирдән дә ишетәм.
   Ачылыр да күк капусы –
   Мин керермен ишектән.

<u>Кушымта</u>:
   *Зәңгәр чәчәкләр – шатлыгың,*
   *Сарысы – сагышларың...*
   *Ишетәм:*
   *– Әнкәй сагынган,*
   *Кайт, – дигән тавышларын.*

4. Ай яктысын шәлләр итеп
   Ябармын иңнәреңә.
   Тагын бер кат сөенерсең
   Дөньяга килгәнемә.

<u>Кушымта</u>:
   *Зәңгәр чәчәкләр – шатлыгың,*
   *Сарысы – сагышларың...*
   *Ишетәм:*
   *– Әнкәй сагынган,*
   *Кайт, – дигән тавышларын.*

# Барыбер якты бу дөнья

М. Мирза

А. Фәйзрахманов

**Allegretto** ♩.=66




17
1. Һәр үт - кән-гә са - ла - ват - ны әй - теп кыл, ке - шем, тәү - бә.
tr
21
Ба - ры - бер як - ты бу дөнь - я, тиң бә-хет юк я - шәү - гә!
25
Ө - ле-шең бар, кө - ме - шең бар, той жы - лы - сын, мул ча - гын,
29
сүн - дер - мә - сен тоз - лы я - шең ө - ме - тең - нең


32
у - ча - гын!.. Күк-тә-ко-яш, ай, йол - дыз-лар бар.
35
Жир-дә-сө-ю, мә - хәб - бәт... Ба-ры-бер як - ты
38
1.
бу дөнь-я, я - шәү-гә тиң юк ләз - зәт...
41
2.
//юк ләз - зәт...
mf




2. Кемгә ни хаҗәт уфтанып
Төн чыгуың утырып.
Кырып ат инде куптарып
Күңелеңнең тутыгын.

<u>*Кушымта*</u>*:*
*Күктә кояш, ай, йолдызлар бар.*
*Җирдә сөю, мәхәббәт...*
*Барыбер якты бу дөнья,*
*Яшәүгә тиң юк ләззәт...*

# Бичура

Л. Зөлкарнәй

А. Фәйзрахманов






2. Бичура, и Бичура,
Ишек катыннан ура –
Хуҗаң җаны урап кайткан,
Ник кертмисең, Бичура?

*Кушымта*:
*Бичура, и Бичура,*
*Булма инде бичара.*
*Күршедәге ятим йортта*
*Яшидер Бибичура.*

3. Бичура, и Бичура,
Бирнәле сандык юра.
Ничә еллар япа-ялгыз
Ник яшисең, Бичура?

*Кушымта:*
*Бичура, и Бичура,*
*Булма инде бичара.*
*Куршедәге ятим йортта*
*Яшидер Бибичура.*

4. Күрше йортның мичләре дә
Ничә ел ягылмаган.
Ничә еллар өстәленә
Ашъяулык ябылмаган.

*Кушымта*:
*Бичура, и Бичура,*
*Бикәчең – Бибичура.*
*...Тәрәздәге такталардан*
*Бишек ясый Бичура*

# Бор атыңны

Ш. Җиһангирова

А. Фәйзрахманов




13
Тойгы белән
Кит-мә ә - ле, җа - ны-ем, ка - я кит - тең? Ни эз-ли-сең чит - ят
16
та - раф - та? Йө-рә-гем-нең сау - лык - ла - рын а - лып,
19
1.
2.
ак-бүз көн-нә-рем- не ка - ралт - ма! //ка - ралт - ма!




2. Артка гына борылып яшен сөртте,
Түзә алмый күзем карашка...
Сарыларга сабышмасын дисәң,
Бор атыңны минем тарафка.

Кушымта:
*Китмә әле, җаныем, кая киттең?*
*Ни эзлисең чит-ят тарафта?*
*Йөрәгемнең саулыкларын алып,*
*Акбүз көннәремне каралтма!*

3. ...Тәрәзәдән генә карап тордым
Атланганын җаныем атларга...
Кайтыр булсаң, каршы чыгармын мин
Ак җанымны түреп акларга.

Кушымта:
*Китмә әле, җаныем, кая киттең?*
*Ни эзлисең чит-ят тарафта?*
*Йөрәгемнең саулыкларын алып,*
*Акбүз көннәремне каралтма!*

# Гөлбишек

С. Әхмәтҗанова

А. Фәйзрахманов




9
Тир-бә-лер-без и-кәү бер-гә мә-хәб-бәт би-ше-ген-дә.
11
Ми-не сө-ю, ба-ры сө - ю я-шә-тә яшь-ле-гем-дә.
13
mf
15
Кабатлау өчен




2. Бәйләм-бәйләм гөлләр китер,
Үрелсен хисләребез.
Аллы-гөлле хыялларга
Күмелсен кичләребез.

<u>*Кушымта:*</u>
*Тирбәлербез икәү бергә*
*Мәхәббәт бишегендә.*
*Мине сөю, бары сөю*
*Яшәтә яшьлегемдә.*

3. Бирәүгә дә бирмим сине –
Тапмадым югалтырга.
Ирек куймам икәү үргән
Хисләрне чуалтырга!

<u>*Кушымта:*</u>
*Тирбәлербез икәү бергә*
*Мәхәббәт бишегендә.*
*Мине сөю, бары сөю*
*Яшәтә яшьлегемдә.*

# Жырым булып калырсың

Р. Фәйзуллин

А. Фәйзрахманов






2. Сизелмичә үтә гомер
Мәшәкатьле көннәр белән.
Гомернең соңгы чигенә
Бараларсың кемнәр белән?
<u>Кушымта</u>:
*Бер суларда агарсыңмы?*
*Бер утларда янарсыңмы?*
*Башларыма кайгы килсә,*
*Яшем булып тамарсыңмы?*

3. Балачакның күге биек!
Оча хыял галәмнәрдә!
Бу дөньяда Ходай үзе
Тәүфикъ бирсен адәмнәргә.
<u>Кушымта</u>:
*Бер суларда агарсыңмы?*
*Бер утларда янарсыңмы?*
*Башларыма кайгы килсә,*
*Яшем булып тамарсыңмы?*

# И кыз бала... (Уйлармы?)

С. Әхмәтҗанова

А. Фәйзрахманов




14
Ку - лым - да ә - ни ор-чы - гы әй - лә-нә зыр - лый - зыр - лый.
3
18
И кыз ба - ла, кыз ба - ла, мо - ңай-ма - ле, түз, ба - ла!
22
Юк - сы-нып ту - ган йор - тын, го - мер и - тә
3
3




2. Төн йокылары күрмәгән
Әнием яшь чагында,
Кул җылыларын тоям күк
Шул җитез орчыгында.

*Кушымта:*
*И кыз бала, кыз бала,*
*Моңаймәле, түз, бала!*
*Юксынып туган йортын,*
*Гомер итә кыз бала.*

3. Чорналган җептәй гомерләр,
Чуалды заманалар...
Уйлармы туган нигез, дип
Без үстергән балалар?

*Кушымта:*
*И кыз бала, кыз бала,*
*Моңаймәле, түз, бала!*
*Юксынып туган йортын,*
*Гомер итә кыз бала.*

# Искә төшкән җыр

Л. Зөлкарнәй

А. Фәйзрахманов






3. Бел, улым, бел, былбыл килгән,
   Улыма тел алып килгән:
   «Үз җырыңның кадерен бел,
   Кем – сандугач, ә кем – тилгән...»
   Бел, улым, бел, былбыл килгән!

4. Уян, улым, куян килгән,
   Таудан юа алып килгән:
   «Тау юасы кебек нык бул,
   Юылма син туган җирдән».
   Уян, улым, куян килгән!

# Каен

Х. Әюп

А. Фәйзрахманов




17
a tempo
Җил - ләр ю - а - тыр ди - сең - ме, се - рең - не сөй - ли - сең - ме?
21
3
3
Без - нең кай - гы - лар - ны ил - гә та - ра - тып йө - ри - сең - ме?
25
Җил - ләр ю - а - тыр ди - сең - ме, се - рең - не сөй -


28
p
mp
3
ли - сеӊ - ме? Без - нен кай - гы - лар - ны ил - гә та - ра - тып йө -
32
Вокализ (Coda)
-ри - сен - ме?
36
rit.
a tempo
Без - нен кай - гы - лар - ны ил - гә




2. Авыл саен, урман саен,
   Юллар саен, чор саен –
   Безнең белән җитәкләшеп,
   Кая барадыр  каен...

<u>*Кушымта*</u>*:*
   *Җилләр юатыр дисеңме,*
   *Сереңне сөйлисеңме?*
   *Безнең кайгыларны илгә*
   *Таратып йөрисеңме?*

# Казанга мәдхия

Роберт Әхмәтҗанов

А. Фәйзрахманов




10
хә - тер-ли ба-рын,
мең яшь-лек Ка-зан,
12
мень - я-шәр Ка-зан!
Си - ңа, ак ка-лам,
14
без - нең яз - мыш-та
из - ге йор - ты-быз
16
бу - лыр-га яз-ган.
Дас - тан-нар җи-ре,


18
яу - гир-ләр и- ле,
мең яшь-лек Ка- зан,
20
меңь - я- шәр Ка- зан!..
22
24
Кабатлау өчен
Тәмамлау өчен
rit.

2. Иркәли җанны Идел һавасы,
Ишетәм синдә әнкәм авазын.
Мәхәббәтем син,
Бәхетем каласы,
Мең яшьлек Казан,
Меңьяшәр Казан!

_Кушымта_:
*Сиңа, ак калам, безнең язмышта*
*Изге йортыбыз булырга язган.*
*Дастаннар җире,*
*Яугирләр иле,*
*Мең яшьлек Казан,*
*Меңьяшәр Казан!..*

3. Һәр ташың синең җанлы, хәтерле,
Сиңа мәдхия Тукайлар язган...
Милләтемнең син
Алтын бишеге,
Мең яшьлек Казан,
Меңьяшәр Казан!..

_Кушымта_:
*Сиңа, ак калам, безнең язмышта*
*Изге йортыбыз булырга язган.*
*Дастаннар җире,*
*Яугирләр иле,*
*Мең яшьлек Казан,*
*Меңьяшәр Казан!..*

4. Кайталар сиңа Сөембикәләр,
Колшәрифләрең калка яңадан.
Бәйсезлек рухы яшәр мәңгегә,
Яшәр мәңгегә,
Мең яшә, Казан!..

_Кушымта_:
*Сиңа, ак калам, безнең язмышта*
*Изге йортыбыз булырга язган.*
*Дастаннар җире,*
*Яугирләр иле,*
*Мең яшьлек Казан,*
*Меңьяшәр Казан!..*

# Кем җылытыр?..

И. Юзеев

А. Фәйзрахманов




11
бер со - рый - сы ки - лә: «Ми - нем хәл - дә ин - де,
13
дөнь - я, әл - лә син дә?» Һа - ва - лар - га ме - неп
15
бер жыр - лый - сы ки - лә: Жа - ным - да - гы боз - лар
17
э - реп тү - гел - сен лә... Шык - сыз бу жи - һан - ны




2. Хыялымнан әкрен... әкрен генә сүнәм...
Җиргә төшәм горур башны иеп.
Дөнья карый миңа үзе өмет белән:
«Суыттыгыз мине, кем җылытыр?..» – диеп.

<u>*Кушымта*</u>:
*Һаваларга менеп бер җырлыйсы килә:*
*Җанымдагы бозлар эреп түгелсен лә...*
*Шыксыз бу җиһанны матурлыйсы килә:*
*«Бөтен дөнья назга-язга күмелсен лә...»*

# Күз тимәсен берүк...

Зөлфәт

А. Фәйзрахманов




16
Ки-ле-шә ак кар-лар ка-ра-шы-ңа! Ак бу-ран-нар ак жыр көй - лә-сен,
20
1.
бө-те-ре-леп жир-гә яу-ган ак-ка тик күз ге-нә ти-я күр - мә-сен...
24
2. Кабатлау өчен
//тик күз ге-нә ти-я күр - мә - сен.
3
9
8
28




2. Күзләреңә синең күз тимәсен,
Ятларга яр була күрмә син.
Ырым сөрмәсен сөрт язмышыңа –
Кайгы синең янда йөрмәсен.

Ырымнар да ярдәм итми икән,
Уйла безнең бергә мәлләрне...
Сагышлардан шулай котылам мин,
Тик шул җиңеләйтә хәлләрне...

# Кызыл чәчәк

Р. Мингалим

А. Фәйзрахманов




17
Са-гы - ну - лар - да я - на - мын, дип, кем - гә дә сөй -
mf
20
лә - мә - дем... Мин hа-ман си - не кө-тә - мен,
23
мин hа - ман сө - ям ә - ле.
25
Кабатлау өчен
f




2. Үтте кышым, сине көтеп
Җәйләргә кердем инде...
Сиңа гына бирер өчен
Гөлләр үстердем инде...

*Кушымта:*
*Сагынуларда янамын, дип,*
*Кемгә дә сөйләмәдем...*
*Мин һаман сине көтәмен,*
*Мин һаман сөям әле...*

3. Су сипсәм дә, ялкын үсте,
Үсте гел кызыл чәчәк.
Синең юллар минем янга
Киләчәк ул, киләчәк.

*Кушымта:*
*Сагынуларда янамын, дип,*
*Кемгә дә сөйләмәдем...*
*Мин һаман сине көтәмен,*
*Мин һаман сөям әле...*

# Минем сагыш

А. Фәйзрахманов

Рәшит Әхмәтҗанов




17
Мин - дә – са - гыш. Си-нең ян-га ба - рыш. Күк - ләр зәң - гәр,
20
бо-лыт та-рал-ган. Йол-дыз бе-лән йол - дыз а - ра - сы - на
23
та - вис кош-лар гү - я юл сал - ган.
1.
25
2.
//юл сал - ган.



2. Көне-төне йөгерсәм дә, хәзер
Мәңгелеккә качкан хыял син.
Үпкән өчен үпкәләдең берчак,
Ай яп-якты, дидең, оял син.

<u>*Кушымта*</u>:
*Миндә – сагыш. Синең янга барыш.*
*Күкләр зәңгәр, болыт таралган.*
*Йолдыз белән йолдыз арасына*
*Тавис кошлар гүя юл салган.*

3. Ә мин, көлеп, айга ачуландым:
Ник карадың, имеш, үпкәндә.
Ай елмайды... Ничек инде хәзер
Кире кайтыйк, диеп, үткәнгә.

<u>*Кушымта*</u>:
*...Кайдан гына эзләп йөрмәдем мин:*
*Гашыйк булган көнем югалган.*
*Йолдыз белән йолдыз арасына*
*Тавис кошлар кемгә юл салган?..*

# Офыктагы юл өстеннән агылалар болытлар...

Р. Фәйзуллин

А. Фәйзрахманов




17
...О - лы юл, ни - гә дип шу - лай үр - ләр-гә мен - дең и - кән?
21
1.
О - фык-та - гы бо - лыт-лар күк, кө - тү — мәң - ге - лек и - кән!
25
2.
лек и - кән!
mf
28




2. Юл югалган шул ноктага
Төбәлгән күзләр күпме!
Кемдер кайта, кемдер китә
Кичеп шул нокта – чикне.

<u>*Кушымта*</u>:
*...Олы юл, нигә дип шулай*
*Үрләргә мендең икән?*
*Офыктагы болытлар күк,*
*Көтү – мәңгелек икән!*

3. Болытлар! Белеп үтегез
Юл өстенең ул турын!
Күпме җаннар шул тарафка
Юнәлткәннәр күз нурын!

<u>*Кушымта*</u>:
*Көтәләр... Ник көтмәсеннәр,*
*Көтәргә өмет барда.*
*Әнә бит болайга таба*
*Йөгерә болытлар да!*

# Сагыш

Халык сүзләре

А. Фәйзрахманов






*2. Агым суның агуы да,*
*Дагалы атның баруы;*
*Кай илләрдә булыр икән*
*Янган йөрәк даруы?*

*3. Җилбер җил искәндә,*
*Тегермән тарта микән.*
*Кеше үзе картаймаса*
*Дөнья картайта икән.*

*4. Суга барып су алып кайттым,*
*Кулбашым талыр инде.*
*Уты бетсә йөрәгемнең*
*Әрнүе калыр инде.*

*5. Бөдрә чәчләрең үреп сал,*
*Без китәбез, күреп кал.*
*Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз*
*Уң битемнән үбеп ал.*

# Син яратсаң...

К. Сибгатуллин

А. Фәйзрахманов




- рыр көн-нәр һа-ман сө - е - неч-ле хә - бәр;
күк-лә - рен-дә ко - я-шы да бай - мас – син я - рат-саң ә -
гәр. //син я - рат-саң ә - гәр.

2. Җиңә алмас кебек беркачай да
Бәлә, каза, зәһәр…
Төннәре дә үтмәс,
Ай да китмәс –
Син яратсаң әгәр.

*Кушымта:*
*Алып килә торыр көннәр һаман*
*Сөенечле хәбәр;*
*Күкләрендә кояшы да баймас –*
*Син яратсаң әгәр.*

3. Чиста тоту кирәк.
Мәхәббәтне
Алдау бик тә хәтәр.
Кичке моңнар мәңге серле калыр –
Син яратсаң әгәр.

*Кушымта:*
*Алып килә торыр көннәр һаман*
*Сөенечле хәбәр;*
*Күкләрендә кояшы да баймас –*
*Син яратсаң әгәр.*

# Сөймәгән бу, димәгез!..

М. Мирза

А. Фәйзрахманов






2. Сөю гөленә уралып
Үрмәгән бу, димәгез.
Хыянәттән ары берни
Күрмәгән бу, димәгез...

Утларына кереп яндым,
Балкыды күңел күгем.
Күпләр елап хатлар язды:
– Булсаңчы бердәнберем!

<u>*Кушымта:*</u>
*Ак болытларга бактым мин,*
*Ак болытта актым мин...*
*Айга менеп Зөһрә кызның*
*Кочагында яттым мин...*

# Су юлы

Рәшит Әхмәтҗанов

А. Фәйзрахманов





Си – ңа га – шыйк йө – рә – гем – не су өс – тен – дә
ут – лар и – теп я – гыйм ә – ле, я – гыйм ә – ле.
//я – гыйм ә – ле.
Кабатлау өчен
Тәмамлау өчен

2. Агымсулар челтер-челтер челтерәде,
Ярны читкә кагыйм әле,
кагыйм әле.
Биек ярга, аннан тауга, аннан талга
Менеп, сине карыйм әле,
карыйм әле.

3. Агымсулар челтер-челтер челтерәде,
Барыйм әле, күзләреңә
багыйм әле.
Су юлында ятлар торса, ят кулыннан
Сине тартып алыйм әле,
алыйм әле.

# Торналар оча
# (Баллада)

Роберт Әхмәтҗанов

А. Фәйзрахманов




9
та - рал - ды-лар тор - на - ла-рым, та -
11
рал - ды - лар төр - ле як - ка...
13
«Са-на-ды- лар», – ди-де бе-рәү, та-рал-ды-лар ял-гыз - ял-гыз...
То-ра ма-лай – си-хер - ләнгән, кым-шан-мый да – кы-зык а - ңа...
15
Бу-раз-на-лар а - ра - сын-да то-ра ма-лай – а-чык а -
Иң бе-рен-че таң кал - ган-дай үзе ач-кан мог-җи - за -


17
1.
2.
Coda
выз.
//га!..
«Җир-дә – ә - би - ләр чу - а - гы,
20
без бу җәй-дә ба-ры ку-нак...»
Тор-на та-вы - шы ка - гыл-са(да),
22
яф - рак ко - я ал - тын ку - -




2. Тезелешеп, күк юлында
Җилфердәшеп очкан чакта
Таралдылар торналарым,
Таралдылар төрле якка...

*<u>Кушымта</u>:*
*Таянып көрәк сабына,*
*Кара җирдә, язып билен,*
*Күк юлына төбәлгән дә*
*Онытылган ялгыз килен;*
*Онытылган...*
*Иңенә шуган*
*Яулыгын да тоймый сыман;*
*Туган җирнең алтын чыңын*
*Онытылып тыңлый сыман...*

# Төп йортым

Роберт Әхмәтҗанов

А. Фәйзрахманов




9
Я - шел кәс - ле төп йор - тым.
10
Бә - хет - ле ке - ше ге - нә я - тып үз тү - шә - ге - нә,
12
ба - гып үз тү - шә - ме - нә, су - ың эч - кән
14
1.
2.
бер йо - тым... //бер йо - тым...




2. Төп йортым син, төп йортым,
   Тургайлы түбәләрем!
   Тәрәзәңдә кемнең бу
   Ак җаны – күбәләге?

<u>*Кушымта:*</u>
   *Бәхетле кеше генә*
   *Ятып үз төшәгенә,*
   *Багып үз түшәменә,*
   *Суың эчкән бер йотым...*

3. Төп йортым бу, төп йортым,
   Бабамнар сөйләшкән җир!
   Чит җирдән бүреге белән
   Кайтырга киңәшкән җир...

<u>*Кушымта:*</u>
   *Бәхетле кеше генә*
   *Ятып үз төшәгенә,*
   *Багып үз түшәменә,*
   *Суың эчкән бер йотым...*

# Туган авылым

Ф. Зариф

А. Фәйзрахманов




12
сең.
Сау - бул - ла - шып,
14
чы - гып кит - кән ба - лаң
бел - ми и - де нәр - сә күү - рә-
16
сен.
Ту - ган а - вы - лым - га-
18
зиз тө - бә - гем,
һәр - чак бул - дың нык - лы те - рә-


20
гем.
21
Ка - бул бул - са и - де син - дә кыл - ган
23
до - га - ла - рым, из - ге те - лә - гем.
Кабатлау өчен
25
mf




2. Яшьлек эзе калган урамыңнан,
   Их, тагын бер җырлап үтәсе.
   Яшел чирәм үскән тау битендә
   Килә тагын атлар көтәсе.

<u>*Кушымта:*</u>

*Туган авылым – газиз төбәгем,*
*Һәрчак булдың ныклы терәгем.*
*Кабул булса иде синдә кылган*
*Догаларым, изге теләгем.*

3. Яшәтәсе, яшәртәсе иде,
   Син яшәсәң, без дә яшәрбез.
   Синдә тудым, синдә үстем, диеп,
   Синең исемең белән яшьнәрбез.

<u>*Кушымта:*</u>

*Туган авылым – газиз төбәгем,*
*Һәрчак булдың ныклы терәгем.*
*Кабул булса иде синдә кылган*
*Догаларым, изге теләгем.*

# Туган туфрак җылысы...

С. Әхмәтҗанова

А. Фәйзрахманов




17
как - са да, га - зиз йор - тын ис - кә а - ла
20
а - дәм ба - ла - сы. Ту - ган ни - гез -
Ту - ган туф - рак -
23
нең жы-лы - сы ү - зе - нә тар - та. Бә - хил-лә - шеп
ның жы-лы - сы ү - зе - нә тар - та. Бә - хил-лә - шеп
27
1.
2.
кит - кән-нәр дә әй - лә-неп кай - та. //та.
кит - кән-нәр дә и - ле - нә кай -




2. Иң татлы бәхет читтә – туган тел тәме,
Йөрәккә шифа бирә моңлы аһәңе.
Еламасны елата,
Уйламасны уйлата,
Туган җирдә генә диеп чын яшәү яме.

<u>Кушымта</u>:
*Туган нигезнең җылысы үзенә тарта.*
*Бәхилләшеп киткәннәр дә әйләнеп кайта.*
*Туган туфракның җылысы үзенә тарта.*
*Бәхилләшеп киткәннәр дә иленә кайта.*

# Тынлык

М. Әгъләмов

А. Фәйзрахманов




11
бу-лып у-ты-рыр-лар һәм те-ләр-ләр из-ге сә-гать-не.
14
Тынычрак
Бер ми-нут-ка тын-лык, әм-ма боз-ма, ак-са-кал-лар кыл-сын до-га-
Син ү-зең-чә те-лә кү-ңе-лең-нән йөр-гән юл-ла-рың-ның у-ңа-
17
1.
сын;
2.
//сын.
19
mf




2. Туган йортка кайтсаң ерак юлдан,
Ташлап кайтма изге гадәтне.
Туган йортың син ил гизеп тапкан
Әдәбеңнән мең кат әдәпле.

<u>*Кушымта*</u>*:*
*Бер минутка тынлык, әмма бозма,*
*Аксакаллар кылсын догасын;*
*Син үзеңчә телә күңелеңнән*
*Йөргән юлларыңның уңасын.*

3. – Даның кайда, малың кайда? – диеп
Сорамаслар синнән, шау килеп,
Бер минутка тынлык.
Ул – мәдхия
Кайтуыңа исән-сау йөреп.

<u>*Кушымта*</u>*:*
*Бер минутка тынлык, әмма бозма,*
*Аксакаллар кылсын догасын;*
*Син үзеңчә телә күңелеңнән*
*Йөргән юлларыңның уңасын.*

# Ул җыр сине эзләп табар әле...

Роберт Әхмәтҗанов

А. Фәйзрахманов




15
ки - лер, эң-гер төш-кәч зәң-гәр кич җи-теп.
18
Ул җыр си-не эз-ләп та-бар ә - - - ле, –
20
бер я-нар - сың дөр-ләп ял-кын - да!
22
Бик е-рак та тү-гел, бик я - кын да –


24
1.
Ул жыр...Ул жыр... си - нең ха - кың- да...
26
2.
Ул жыр...Ул жыр... си - нең ха - кың- да...
28
2. Тәмамлау өчен
Ул жыр...Ул жыр... си - нең ха - кың- да...
mf
31

2. Мин ул җырны сиңа атап юллыйм,
Бер сагынсын диеп Киләчәк.
Ник тыңладым, диеп, укенерсең,
Ул киләчәк сиңа киләчәк!..

<u>*Кушымта*</u>*:*
*Ул җыр сине эзләп табар әле, –*
*Бер янарсың дөрләп ялкында!*
*Бик ерак та түгел, бик якын да –*
*Ул җыр... Ул җыр... синең хакында...*

3. Ул җыр сине бер уятыр әле,
Мең уйлатыр әле яңадан.
Күңел яраларын дәваларга
Табылмас шул, булмас дәвалар!

<u>*Кушымта*</u>*:*
*Ул җыр сине эзләп табар әле, –*
*Бер янарсың дөрләп ялкында!*
*Бик ерак та түгел, бик якын да –*
*Ул җыр... Ул җыр... синең хакында...*

# Ышаныч

Р. Фәйзуллин

А. Фәйзрахманов




10
ө - чен жан а(я) - мый я - шәү - че - ләр и - реш -
12
Кушымта:
сен - нәр те - лә - ге - нә! Җир йө - зен - дә күп - ме
14
а - на ба - ла ба - га, ө - мет - лә - неп ты - ныч
16
көн - гә, як - ты көн - гә! Һәм - мә ке - ше шат я -


18
шә - сен, бә - хет жы - рын жыр - лый - жыр - лый ту - ган
20
жир - дә, ту - ган тел - дә! Һәм - мә ке - ше шат я -
22
шә - сен, бә - хет жы - рын жыр - лый - жыр - лый ту - ган
24
Кабатлау өчен
жир - дә, ту - ган тел - дә!




2. Гөл чәчәкле, алсу таңлы бу дөньяга
Туа кеше бәхет өчен, шатлык өчен.
Ил язмышы кыл өстендә торса әгәр,
Фидаиләр башын сала хаклык өчен.

_Кушымта:_
*Җир йөзендә күпме ана бала бага,*
*Өметләнеп тыныч көнгә, якты көнгә!*
*Һәммә кеше шат яшәсен, бәхет җырын*
*Җырлый-җырлый туган җирдә, туган телдә!*

# Юрау

Зөлфәт

А. Фәйзрахманов




13
Һәр төш - не дә ак бә - хет - кә ю - рап,
15
куп - не кө - теп го - мер ү - тел - де... Як - ты и - де без - нең
18
саф ө - мет - ләр! - Таң Ко - шы - ның тө - ше ши - кел - ле.
1.
21
2.
ши - кел - ле.
Тәмамлау өчен
mf




2. Нинди төшләр кирәк икән сиңа
Йөргәндә мин ерак-еракта? –
Агын – карасын да төшләреңнең
Ятларга син бары юратма!

*Кушымта:*
*Һәр төшне дә ак бәхеткә юрап,*
*Күпме көтеп гомер үтелде...*
*Якты иде безнең саф өметләр! –*
*Таң Кошының төше шикелле.*

3. Булсын сөю
Учак төбендәге
Сүнү белми торган бер күмер...
Табигать тә юрый алмый торган
Уртак бер төш булсын бу гомер!

*Кушымта:*
*Һәр төшне дә ак бәхеткә юрап,*
*Күпме көтеп гомер үтелде...*
*Якты иде безнең саф өметләр! –*
*Таң Кошының төше шикелле.*

# Язгы буран

Р. Вәлиев

А. Фәйзрахманов




9
1.Тыш-та бу-ран, яз бу-ра-ны – туз-гый йол-дыз ту-за-ны.
11
Си-зэм: яз-гы бу-ран ке-бек ду-лап го-мер уз-ган-ны.
13
Ду-лап го-мер уз-ган-ны.
15
Яз-гы бу-ран, наз-лы бу-ран – мэ-хэб-бэт бу-ран-на-ры.


1.
Ми-не ник-тер чит-ләп үт-те, җа-ны-ма у - рал-ма - -
-ды. //җа-ны-ма у - рал-ма - - ды.
2.
Тәмамлау өчен
mf




2. Тынды буран. Буран белән
Бар дөнья сүнгән, тынган...
Кем җылытыр күңелемне?
Алда – яз, ә мин туңам.

<u>Кушымта</u>:
*Язгы буран, назлы буран –*
*Мәхәббәт бураннары.*
*Мине никтер читләп үтте,*
*Җаныма уралмады.*

# Янәшәдән парлап очкан чакта...

С. Әхмәтҗанова

А. Фәйзрахманов









2. Яраланган коштай бәргәләнә,
Бу йөрәкне ничек юатыйм?
Ялгыз канат белән очуларның
Газапларын ничек аңлатыйм?

3. Икәү иңләп гизгән киңлекләрне
Кочарга дип күңел талпына.
Күтәреләм сыңар канат белән,
Сиңа биргән вәгъдәм хакына.

# Яшьлегемә кире кайталмыйм

С. Әхмәтҗанова А. Фәйзрахманов




17
«Туп-туп» ит - кән то-як та-вы-шы-мы, йөрәк ти-бе-ше-ме – әй-тал-мыйм...
21
1.
Тал-пын-са да күңел, аш-кын-са да, Яшь-ле-ге-мә ки-ре кай-тал-мыйм.
25
2.
//кай - тал - мыйм.
mf
5
29




2. Йөгән кидерелгән ярсу җанны
Җибәрәсе иде тугарып.
Ат саклаган төнге болыннарга
Килдем, ахры, шактый соңарып.

Кушымта:
*«Туп-туп» иткән тояк тавышымы,*
*Йөрәк тибешеме – әйталмыйм...*
*Талпынса да күңел, ашкынса да,*
*Яшьлегемә кире кайталмыйм.*

3. Гармунымны алып җырлап карыйм,
Моң да башка, көй дә ят бүген.
Алмачуарымның күзләредәй,
Күңел мөлдерәмә чак бүген.

Кушымта:
*«Туп-туп» иткән тояк тавышымы,*
*Йөрәк тибешеме – әйталмыйм...*
*Талпынса да күңел, ашкынса да,*
*Яшьлегемә кире кайталмыйм.*

# ЭЧТӘЛЕК


| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | «Авылда көз» | *Р. Фәйзуллин сүзләре* | 10 |
| 2. | «Ана җыры» | *С. Әхмәтҗанова сүзләре* | 14 |
| 3. | «Атларга йөгән кидермим…» | *Җ. Сөләйман сүзләре* | 18 |
| 4. | «Атларым-канатларым» | *Х. Туфан сүзләре* | 22 |
| 5. | «Ашкыну» | *Р. Фәйзуллин сүзләре* | 26 |
| 6. | «Әнием» | *Җ. Сөләйман сүзләре* | 29 |
| 7. | «Әнкәйнең чәчәкләре» | *Рәшит Әхмәтҗанов сүзләре* | 33 |
| 8. | «Барыбер якты бу дөнья» | *М. Мирза сүзләре* | 36 |
| 9. | «Бичура» | *Л. Зөлкарнәй сүзләре* | 40 |
| 10. | «Бор атыңны» | *Ш. Җиһангирова сүзләре* | 42 |
| 11. | «Гөлбишек» | *С. Әхмәтҗанова сүзләре* | 45 |
| 12. | «Җырым булып калырсың…» | *Р. Фәйзуллин сүзләре* | 48 |
| 13. | «И кыз бала...» («Уйлармы?») | *С. Әхмәтҗанова сүзләре* | 50 |
| 14. | «Искә төшкән җыр» | *Л. Зөлкарнәй сүзләре* | 53 |
| 15. | «Каен» | *Х. Әюп сүзләре* | 55 |
| 16. | «Казанга мәдхия» | *Роберт Әхмәтҗанов сүзләре* | 59 |
| 17. | «Кем җылытыр?..» | *И. Юзеев сүзләре* | 63 |
| 18. | «Күз тимәсен берүк» | *Зөлфәт сүзләре* | 66 |
| 19. | «Кызыл чәчәк» | *Р. Мингалим сүзләре* | 69 |
| 20. | «Минем сагыш» | *Рәшит Әхмәтҗанов сүзләре* | 72 |
| 21. | «Офыктагы юл өстеннән агылалар болытлар…» | Р. *Фәйзуллин сүзләре* | 75 |
| 22. | «Сагыш» | *Халык сүзләре* | 78 |
| 23. | «Син яратсаң…» | *К. Сибгатуллин сүзләре* | 80 |
| 24. | «Сөймәгән бу, димәгез!» | *М. Мирза сүзләре* | 83 |
| 25. | «Су юлы» | *Рәшит Әхмәтҗанов сүзләре* | 85 |
| 26. | «Торналар оча» (Баллада) | *Роберт Әхмәтҗанов сүзләре* | 88 |
| 27. | «Төп йортым» | *Роберт Әхмәтҗанов* | 92 |
| 28. | «Туган авылым» | *Ф. Зариф сүзләре* | 95 |
| 29. | «Туган туфрак җылысы…» | *С. Әхмәтҗанова сүзләре* | 99 |
| 30. | «Тынлык» | *М. Әгъләмов сүзләре* | 102 |
| 31. | «Ул җыр сине эзләп табар әле» | *Роберт Әхмәтҗанов сүзләре* | 105 |
| 32. | «Ышаныч» | *Р. Фәйзуллин сүзләре* | 109 |
| 33. | «Юрау» | *Зөлфәт сүзләре* | 113 |
| 34. | «Язгы буран» | *Р. Вәлиев сүзләре* | 116 |
| 35. | «Янәшәдән парлап очкан чакта…» | *С. Әхмәтҗанова сүзләре* | 120 |
| 36. | «Яшьлегемә кире кайталмыйм | *С. Әхмәтҗанова сүзләре* | 122 |

Кереш мәкалә авторы, җыентыкны төзүче – Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты,
профессор, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премия лауреаты,
Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең һәм Татарстан Республикасы
фольклор музыкасы дәүләт ансамбленең сәнгать җитәкчесе

**А. Ф. ФӘЙЗРАХМАНОВ**

**ҖЫРЫМ БУЛЫП КАЛЫРСЫҢ...**

җырлар һәм романслар

Редакторы һәм төзүчесе Татарстанның атказанган артисткасы Г. Ф. Шәрапова

Ноталарны язды И. И. Фәйзетдинов

Музыкаль редакторы һәм компьютерда биткә салучы И. Ф. Камалов

Тышлык дизайны Б. Садовников

© А. Ф. Фәйзрахманов, 2021 ел.

Тиражы 500 данә.

«Халкыбыз мирасы» нәшриятында басылды.
420073, Казан шәһәре, Спортивная, 33.